

Россия Федерациясенен кvп тобәкләрен vз иткән балтырган – борщевик Мордовиядә дә артканнан-арта. Урыны-урыны белән буе оч метрга житvче бу vсемлекне хәзер инде республиканын теләсә кайсы тобәгендә кvрергә була. Олы юл тирәләрендә, тимер юл буйларында да артканнан-арта бу әрсез vлән.
Белгечләр әйтvенчә, бер vлән ким дигәндә 20 мен орлык бирергә сәләтле! Ашыгыч рәвештә чарасын кvрмәгәндә, мондый хәлнен аяныч нәтижәләргә китерvен кот тә тор.
 - Борщевик Сосновского был завезен более 30 лет назад в ботанический сад Мордовского госуниверситета в качестве демонстрационной культуры, на Мордовскую государственную сельскохозяйственную опытную станцию, а также в Краснослободский сельскохозяйственный техникум для научных исследований как перспективное кормовое растение, - ди Н.П. Огарев исемендәге МГУнын Аграр институты авыл хужалыгы белеме кандидаты, агрономия һәм ландшафлы архитектура кафедрасы доценты  Александр Никольский.       – Именно из этих трех мест борщевик Сосновского начал свое распространение по территории республики. Особенно его много в Ромодановском и Лямбирском районах. В Теньгушевский и Зубово-Полянский районы борщевик попал уже со стороны Москвы – семена растения были разнесены колесами автомобилей.
Масштабы распространения борщевика в Мордовии за последние десять лет уже можно считать серьезной проблемой. Почему он разрастается так стремительно? Этот сорняк очень неприхотлив, растет на всех почвах и в любых условиях. Одно растение дает 2-3 тысячи семян – ими можно засеять целое поле. Неслучайно борщевик Сосновского занесен в Черную книгу флоры России, в которой перечислены растения, наносящие вред другим растениям и даже людям.
Бу vләннен кеше организмына никадәрле куркыныч икәнен һәркем белә. Ана кагылып кына vтv дә тәндә жәрәхәт барлыкка китерергә момкин. Кайчагында кычыткан чагуын хәтерләтvче балтырган агуы тәннен тырналган урынына эләксә, авыр жәрәхәткә әйләнергә дә момкин. Мондый вакытта кичекмәстән табибларга морәжәгать итәргә кирәк. Ел саен дистәләрчә кеше әлеге vләннән зур зыян кvреп, хәтта хастаханәләрдә ятып чыга. Балтырган бигрәк тә балалар организмы очен куркыныч. Анын белән корәшv шактый авыр. Үсемлекнен тамырлары кайчагында беләк юанлыгына житә икән. Тирәнлеге дә берничә метрдан арта, диләр.

Тармакланып vскән балтырган та-мырларынын берсен казып алсан – икенчесе, анысын алсан, оченчесе сак-лана, ди белгечләр.
- Балтырганга каршы корәш очен чыгымнар шактый кирәк. Бер селтәнv белән генә әлеге афәттән котыла торган тvгел бит. Кайчагында берничә ел рәттән эш алып барып кына тиешле нәтижәгә ирешеп була, ди белгечләр сvзенә кушылып бакчачы Юрий Лямин Саранскткан. – Бакчама биш ел элек кырлардан кvчкән иде. Чалгы белән чабып та карадым, балта белән дә, яндырдым да – булышмады. Галимнәр бу vләннен элегрәк коелган орлыкларынын тишелеп чыгу сәләте 12 елга сузыла, диләр. Агулы икәнен белә идем, әмма букадәр дип уйламадым. Аяк-кулымны пешереп дәваханәгә дә эләктем. Бvген тулы экипировка – резин перчаткака һәм итекләр, кvзләргә очки киеп чабам. Гербицидлар да кулланам, әмма файдасы аз. Киләсе елга шундый ук кvренеш кайта. Мона хужасыз дачалар да сәбәп булып тора. Аларга штраф тvләтергә кирәк; шундый программалар кайбер регионнарда эшли һәм нәтижәсе унай.
Александр Никольский балдырганны жинеп булуына ышана. Шуна диссертациясен багышлаган. Биш тапкыр чабып караган ул, гирбицидлар кулланган, әмма теләгән нәтижәгә ирешмәгән. «Ин гади һәм эффектлы юл: зур vсемлекнен чәчәк атыр алдыннан «корзинка»ларын кисеп алу. Шулай борщевик vлә һәм орлыклары да калмый. Бу vсемлек гомерендә бер тапкыр гына чәчәк ата икән», - ди авыл хужалыгы  фән докторы.

**Н. Хәлил**